ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 407 от «14» 11 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 374 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге "Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) бер мәртәбә акчалата түләү бирү һәм Россия Федерациясе гражданннарына (чит ил гражданнарына) махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында" 374 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 374 нче карары белән расланган Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибендә:

1.1.1. 3 пунктның 3.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге тәртипне үтәүне оештыру өчен җаваплы вәкаләтле заты булып Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) – (алга таба – Секретарь) тора.»;

1.1.2. 3.9 пунктта «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе» сүзләрен «Секретарь»сүзенә

0000012434

алмаштырырга.;

1.2. Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) бер мәртәбә акчалата түләү бирү һәм Россия Федерациясе гражданнннарына (чит ил гражданнарына) махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга бер мәртәбә акчалата түләү бирү буенча Комиссия составын Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 16.10.2024 ел, 374 номерлы карары белән расланган кушымта нигезендә яңа редакциядә (килешү буенча) бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.М.Ефимовка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гарипов

Башкарма комитеты карарына
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының
14.11.2024 - №407 карарына
кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) бер мәртәбә акчалата түләү бирү һәм Россия Федерациясе гражданнарына (чит ил гражданнарына) махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүдә ярдәм күрсәткән затларга бер мәртәбә акчалата түләү бирү буенча**

**КОМИССИЯ СОСТАВЫ (килешү буенча)**

| | |
|---|---|
| Р.Р. Сәмигуллин | комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Р.М. Гарипов | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары |
| А.М. Ефимов | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| И.Р. Шафеев | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының эшләр идарәчесе; |
| И.М. Фәтхуллин | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының хокукый эш бүлеге башлыгы |
| В.Н. Фәизов | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| А.В. Синкевич | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының хәрби комиссары (килешү буенча) |
| А.М. Сергеев | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча). |